

Матур сентябрьдә Мордовия Республикасы А.С.Пушкин исемендәге милли китапханәнен туган телне һәм туган якны өйрәнv әдәбияты бvлегенен баш китапханәчесе Альфия Нургаян кызы Маланьчева житәкчелегендә, Пушкинканын 2 меннән артык булган китаплы татар әдәбияты секторында “Татар шигърияте доньясы” дигән чара vтте.
Кичәдә Үзәк Диния нәзарәте (ЦДУМ РМ) имам-хатыйбы, балалар һәм яшьләр белән эшләv буенча Саранск шәһәре рухи-мәдәни vзәге белгече Няиль Равиль улы Сабитов, «Юлдаш» ижтимагый-сәяси газета атказанган хәбәрчесе Наилә Халил кызы Насырова, Мордовиянен атказанган жырчысы Гюзель Нәим кызы Казакова, Рузаевка районы Татар Пешлә “Бит-21” модель китапханәчесе Леана Наиль кызы Чавкина, Ләмберә беренче урта мәктәбе укытучысы Алмаз Кериш кызы Янгляева катнашылар.
Чараны Альфия Нургаян кызы Маланьчева алып барды һәм кичәнен эпиграфы иттереп Татарстан халык шагыйре Сибгат ага Хәкимнен “Анын бердәнбер максаты – халыктан алган шигъри таланты белән шул халыкка хезмәт итv” сvзләрен алган. Альфия Нургаян кызы татар поэзиясенен тарихы, бvгенгесе турында мәгълуматны презентация ярдәмендә ишеттерде, шигырьләр укыды. Торле чорда язылган һәм торле темага багышланган шигырьләрне укучылар, укытучылар сәнгатьле укыдылар. Бергәләп “Туган тел” жырын жырладык.
Мордовиянен атказанган мәдәният хезмәткәре, кvп кенә жыр конкурслары лауреаты Гvзәл Нәим кызы Казакова жырлары катнашучыларнын йорәкләрен яулап алды: рәхәтләнеп, сокланып тынладык. Анын чыгышы кичәнен vзенчәлекле бизәге булды.
Чакырылган барлык кунаклар да кичәдә актив катнаштылар. Чарада Няиль Равиль улы Сабитов Ватаныбызда рухи һәм милли кыйммәтләр, тормышыбызда телнен роле турында, яшьләргә vзәкнен vсеп килvче буын очен башкарган моһим эше турында сойләп, vгет-нәсыйхәт сvзе белән морәжәгать итте. Матур кичә оештыручыларга, катнашучыларга рәхмәтләрен дә белдерде.
Наилә Халил кызы Насырова, татар шигъриятендә якташ язучылар турында сойләп, Мордовиянен халык шагыйре Камиль Тангалычевнен Ркаил Зәйдулла тәржемәсендә “Туган тел” һәм якташы Һади Такташка багышлап язган “Сыркыды авылы” шигырьләрен кичәдә катнашучыларга ишеттерде.

